КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 4 ноябрь г.Казань № 992

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының тәңгәллеген билгеләү комиссиясен төзү турында» 2003 ел, 29 май, 295 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының тәңгәллеген билгеләү комиссиясе составына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының тәңгәллеген билгеләү комиссиясен төзү турында» 2003 ел, 29 май, 295 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2003 ел, 21 июль, 381 нче; 2009 ел, 23 ноябрь, 795 нче; 2011 ел, 21 гыйнвар, 36 нчы; 2012 ел, 10 май, 364 нче; 2019 ел, 16 июль, 584 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының тәңгәллеген билгеләү комиссиясе составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

комиссия составыннан Н.Ш.Тимергалинаны, И.Г.Пеньковаңы чыгарырга;

комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу бүлеге төп киңәшчесе Лия Владимировна Басованы;

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының пенсия һәм тиешле елларны эшләгән өчен пенсия билгеләү һәм аларга өстәмә түләү бүлеге башлыгы Залинә Таһир кызы Диярованы.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин